


**10 тиен**

*Рафиков Мазит Магсумович*

ГАФФАР — МАСТЕР НА ВСЕ РУКИ

Сказки и стихи


(на татарском языке)

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов.* Художество редакторы *Р. Шәмсетдинов.* Техник редакторы *Л. Тилк.* Корректоры *И. Хәнипова.* ИБ № 3444. Наборга бирелде 31.08.83. Басарга кул куелды 23.03.84. Формат 70×90 1/16. 80 гр. офсет кәгазе № 2. Гарнитура литературная. Печать высокая. Якынча басма табагы 1,8. Учетн.-изд. табагы 1,8. Усл. кр. отт. 3,0. Тираж 20 000. Заказ 3-489. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19


Мәҗит Рафиков

# ОСТАКУЛ ГАФФАР һәм КЫРЫК ЮЛБАСАР





Мәҗит Рафиков

# ОСТАКУЛ ГАФФАР ҺӘМ КЫРЫК ЮЛБАСАР

ӘКИЯТЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1984

ББК 84.3Тат.
Р27

*КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА*

Художнигы *Степан Кульбака*

**Рафиков М.**

Р27 Остакул Гаффар һәм кырык юлбасар: Әкиятләр, шигырьләр.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.— 24 бит.

**Бу китапка авторның балаларга атап язган кызыклы әкиятләре һәм шигырьләре керде.**

**Р** $\frac{4803010200-091}{М132(03)-84}$ **189—84** **ББК 84.3Тат.**

© Татарстан китап нәшрияты, 1984



# ОСТАКУЛ ГАФФАР ҺӘМ КЫРЫК ЮЛБАСАР ТУРЫНДА ТАБЫШМАКЛЫ ӘКИЯТ

Тән азыгы — икмәктер,
Җан азыгы — хикмәттер.

*Мәкаль*

1

Борын-борын заманда
Әтәч йөзгән Кабанда,
Торна йөргән сабанда,
Чуртан торган аранда,—
Менә шушы заманда,
Әллә ялган, әллә чын,
Гаепләштән булмасын,
Казан — Арча арасы гел
Кара урман булган ди,
Шул урманда юлбасарлар
Ята торган булган ди.
Өчәү түгел, җидәү түгел,
Үзләре кырык икән,
Базарчының-юлаучының
Эшләре шырык икән.
Кара яр чокыры икән
Кара эшләр оясы:
«Җаныңмы?» дип,
«Малыңмы?» дип
Балта-пычак уйнасынмы,
Юлчымы кан еласын...
Күпме акча, алтын-көмеш,
Күпме товар, күпме ат,
Толып, билбау, киез ката,
Чыбыркы, ыштыр, чабата
Талап җыйган ди явызлар,
Күпме җан булган харап! —
Монысы инде чын да чын,
Гаепләштән булмасын.

2

Мәшһүр Арча төбәгендә
Торган ди Гаффар агай.
Ни базарчы, ни бай түгел,
Кыю да түгел алай...
Кем булсын? Билгеле инде,
Атсыз-җирсез бер мужик.
Кая аңар фырт киенеп
Йөрү шәп атлар җигеп!
Бер авылда мич салган ди,
Шуның тиярен алган ди,
Менә сөенә-сөенә
Ашыга ди өенә.
Урман куе, алда тау...
Өстә чикмән, билдә бау,
Бүрке кыңгыр,
Үзе елгыр,



Капчыгы буш,
Күңеле хуш.
Шик-шөбһәсез
җырлый-җырлый
Кайтып килә ди Гаффар.
— Ну туныйбы-ы-ыз! — диеп
кыҗрап
Тора кырык юлбасар.

3

Гаффар — гомере бу эштә! —
Гөнаһсыз, гүя фәрештә,
Уйламыйча аны-моны
Узып бара ди чокырны.
Менә кинәт юлбасарлар
Балта-чукмарлар тотып
Килде-чыкты ике яктан,
Тотып ашардай булып:
— Чү, сәүдәгәр,— диләр
моңа,—
Бир суманы, укы доганы!
Чыкса тавышың, бетте башың,
Кистән белән тондырам!..—
Бу юлчыны кырык куллап
Этеп-төртеп ектылар ди,
Чикмәненең эчен-тышын,
Уң кесәсен, сул кесәсен
Капшап-тентеп чыктылар ди:
— Ни алтын, ни көмеш,
Хәерчедер бу! — имеш.

Менә эчке бер кесәдән
Килеп чыкты ди байлык —
Көмеш тәңкә төреп салган
Ап-ак кына кульяулык.



2 3-489

Төште-китте акча җиргә,
Ялтыр-йолтыр ялтырап,
Керде-китте ди үләнгә
Чалтыр-чолтыр чалтырап.

Ташланды ди юлбасарлар
Үлән йолкып эзләргә.
Күренми ди хәләл акча
Харам сөйгән күзләргә.
Этешә ди, төртешә ди,
Кырык җилкә, кырык баш:
— Син тапкансың!
— Син йомгансың! —
Китте ди орыш-талаш.
Каный башлар, шешә күзләр,
Кайсыларның кул сынык...
Менә нинди була икән
Юлбасарлар дуслыгы!
Бик мәзәк бу тамашага
Карап катты ди Гаффар...
Исенә килеп җан-фәрманга
Торды-чапты ди Гаффар.
Куркуыннан Гаффарның ди
Коты җиткән ботына.
Белгәненчә укына ди
Чабып барган хутына:
— Йа ходай, йа ходай,
Ко... ко... котылдым бугай...—
Йөгерде ди тау менгәнче,
Җиде тире акканчы,
Йорәге шартлардай булып,
Җан сулуы капканчы.
Үргә чыкты. Хәлдән таеп
Утырды ди. Ятты ди...
Хәл алгач, болытка карап
Үз-үзенә әйтте ди:
— Төкер, Гаффар, җый исеңне,
Бу бит, малай, дөньядыр!
Бер түгел, җиде үлемнән
Калучылар буладыр...

Бер акча да бер кулъяулык —
Шул да булдымы байлык!
Газиз башың сау булсын да
Ике кулың бар булсын.

4

Ярый, торды, өстен какты,
Атлый бирә ди Гаффар.
(Бүтәннәрне сагалыйдыр
Артта кырык юлбасар.)
Көлә Гаффар: — Уйлап баксаң,
Юлбасарлар — юләрләр!
Кешенең зур байлыгын
Кесәдә дип беләләр...
Кесә байлыгының аның
Килүе дә китүе!
Юк, малай, кесәдән генә
Тормый дөнья көтүе...
Шушы ике кулым белән
Сөреп-чәчеп, урып-сугып
Иген дә игә беләм,
Пычкы көйләп, балта чарлап,
Урман да ега беләм,
Утын да турый беләм,
Өйләр дә бурый беләм,
Күмер яга да беләм,
Такта яра да беләм,
Кәрниз сузып, бәпкә куеп
Түбә яба да беләм.
Курыс төшерә беләм,
Чабата үрә беләм,
Аркан ишә, чыпта суга,
Тәртә дә бөгә беләм,
Эшем белән, сүзем белән
Олыларның-кечеләрнең
Күңелен күрә беләм.
Болыннарда печән чаба,
Кибән коя да беләм,





Сузылып төшеп ял итәргә
Куыш кора да беләм.
Калыбына салып кына
Итек тегә дә беләм,
Аллы-гөлле бизәк тезеп
Читек чигә дә беләм.
Бакча да үстерә алам,
Атлар да карый алам,
Капка ачып, сыйлар куеп
Дусларга ярый алам.
Умарта да асрый беләм,
Балын да җыя беләм,
Ачысыннан-төчесеннән
Мәен дә коя беләм —
Җырлый гына бел, кунак,
Бии генә бел, кунак,
Бу дуслыкның, татулыкның
Кадерен генә бел, кунак!..

Саный китсәң, саный китсәң,
Бармак саен биш һөнәр.
Ничек хәерче булыйм мин,
Уйлап кара син, юләр!
Өемә тереклек керткән
Шушы куллар түгелме?
Җаныма мең шатлык биргән
Шушы куллар түгелме?
Бар гомеремә нур өргән
Шушы куллар түгелме?!
Үз акылың бик җитмәсә,
Әүлияләрдин сора:
Шушы ике эшчән кулың —
Дөнья бәясе тора!
Күңелем шат бу дөньяда:
Ике оста кулым бар.
Юлбасар ул, баеса да,
Көне кара, юлы тар...—

Бу уйлардан горурланып,
Масаеп бара Гаффар.
Ә бераздан башын салып,
Моңаеп ала Гаффар:
— Ай, гаделсез лә бу дөнья!
Баш иялəр байлыкка.
Ни хөрмәт юк, ни почет юк
Эш каерган халыкка.
Без иксәк, бай җыеп китә,
Без тексәк, киеп китә,
Без җиксәк, алар утырып:
— Һи-и, ахмак! — диеп китә.
Мич чыгар — байлар
җылынсын,
Сиңа — эше, балчыгы;
Аларга аш, аларга сый,
Сиңа ләксен валчыгы...
Байлар эчсә, кәеф чиксә,
Без фәкыйрьнең баш чатный.
Безнең нужа, безнең кайгы
Алар күңелен кузгатмый.

Уйлана безнең Гаффар,
Моңлана безнең Гаффар:
«Карурманны чыккан чакта
Атым китте су буйла-а-а-ап,
Ай-и-и-и-и,
Мин саргаям сезне
уйла-а-а-ап...»

— Әмма гел болай тормас,—
ди,—
Эш, иҗат өскә чыгар,
Тырышлыкка, осталыкка
Җыр багышлар шагыйрьләр.
Килер,— ди ул,— кайчан да бер
Шундый гадел бер заман,
Байлык түгел, эшең белән
Зурларлар сине һаман.
Күбәер зирәк акыллар,
Чыгар яңа һөнәрләр,
Кешеләр иҗат-хезмәттән
Бәхет-ләззәт чигәрләр.
Вәт булыр гүзәл заман! — дип
Уйлый башлый ди Гаффар,
Түбәсе күккә тигәндәй,
Җырлый башлый ди Гаффар:
«Эш эшләвең — бәйрәм булсын,
Ай-һайлүк лә,
Юл йөрүең — сәйран булсын,
Ай-һайлү-ү-ү-ук!..»


Куанычтан барган хуттан
Бии башлый ди Гаффар,
Очынып китеп, кыю уйлар
Уйлый башлый ди Гаффар:
— Их, сау булып, шул бәхетле
Заманда торсаң икән дә,
Оста куллар арасында
Беренче булсаң икән!..

Валлаһи да, билләһи дә,
Юлбасарлар — юләрләр!
Кешенең иң зур байлыгын
Кесәдә дип беләләр...
Юк бит, малай, чын байлык
ул —
Кулдан килер эшләрең,
Тырышлыгың, осталыгың,
Якты күңел хисләрең!

Иң атаклы байга да бит
Кирәк ныклы каравыл:
Йорты янса я таланса,
Хәерчегә кала ул.

Мине хет кырык юлбасар
Шәрә калдырып тала —
Бу һөнәрләрем барыбер
Үз кулларымда кала!







Утта янмас, суда батмас
Һәм таланмас байлыгым!
Бу байлыгым бар чагында
Мәңге йөрмәм кайгырып.

Тереклекнең чишмәсе шул
Эшчән кулдан башлана.
Житмеш жиде һөнәр бел син,
Әмма берсен ташлама!

Эштән туймас бу кулларым,—
Жанымның мең шатлыгы,
Вөжданымның сафлыгы да
Бу йөземнең аклыгы.

Юлбасарлы бу сәфәрдин
Кайтып килә ди Гаффар,
Бүрке кыңгыр,
Үзе елгыр,

Кесәсе буш,
Капчыгы буш,
Корсагы буш,
Күңеле хуш!

Менә өе. Аяк атлап
Керер хәле калмагач,
Кычкыра ди: — Алла бирсә,
Хатын, тизрәк ишек ач!
Сәфәр унды,— дигән була,—
Юлбасарлар очраттылар,
Бер тәңкәгә мәңгелек бер
Акыл биреп озаттылар...—

Табын янында борычлап
Итле ашны сукты ди,
Жиде яшьлек улын сөеп
Маңгаеннан үпте ди:



— Улым, улым, уң кулым,
Уң кулым син, күз нурым,
Әйтим сиңа табышмак,
Тапкыр булсаң, уйлап тап:
Кесәгә салынмый ул,
Кесәдән алынмый ул,
Тотарга бирелми ул,
Күзгә дә күренми ул...

Тотарга да бирелмәгәч,
Күзеңә дә күренмәгәч,
Үзе бер дә юк кебек,
Бәясе дә чүп кебек,
Әмма ансыз
Кеше сансыз!
Бу ни була?
Я уйла!

Бу синең иң зур байлыгың,
Бу байлыгың — гомерлек.

Дөньяның бар алтыннары,
Көмешләре, жәүһәрләре,
Алмазлары, якутлары,
Төрле асылташларының
Барсына да торырлык.
Үзе гел яңара торыр,
Черемәс ул, таркалмас,
Үзен кырык юлбасар да
Синнән талап алалмас...

Я уйла, я уйла,
Бу нинди байлык була?

Беләм инде, табалмассың,
Син шул әле яшерәк.
Әмма, улым, бу хикмәтне
Яшьтән белергә кирәк.
Тыңла, әйтим, күңелеңә
Ятсын асылташ булып:



БАШТА — АКЫЛ,
КУЛДА — ҺӨНӘР,
КҮҢЕЛЕҢДӘ — ЯХШЫЛЫК!

Бусы инде иң чыны,
Онытма, улым, шуны.

Моны үзең белү җитмәс,
Дустыңа да сөйләрсең.
Кем өйрәтте, дип сораса,
Үзем белдем, диярсең.

* * *

Бүген яттым, кичә тордым,
Илла әйбәт төш күрдем:
Кара яр чокырына бардым,
Теге кырык юлбасарның
Ояларын өшкердем.
Кырыгысын бер янчыкка
Төйнәп бозга катырдым,
Таш бәйләдем, әфсен әйттем,
Казан суына батырдым...
Ышанмасаң, барып кара,
Автобус алып бара!

## ТӨЛКЕ УЛЫ ХӘЙЛӘПҮШ

Тауда йөреп, дөнья күреп
Кайтты бер көн Хәйләпүш.
— Гаҗәп икән хәлләр! — диеп
Әйтте бер көн Хәйләпүш.

«Юлда йөри, кырда гөрли,
Дөнья тулы машина!
Мин дә берне ясыйм!» дигән
Ният килде башына.

«Мин бит Майлы Мыек белән
Кызыл Койрык баласы.
Миңамы хәйлә-хикмәтне
Кешедән сорап аласы?!»

Тимер алды, агач тапты,
кучәр чапты,
Көпчәк кисте, такта уйды,
тартма куйды,
Кадак какты, эрҗә такты,
буяу якты,

Номер сукты кашына,—
Вәт булыр бу машина!

«Менеп утырыйм әле,
Гөрләтеп йөрим әле!
Һай! Йөрми бит. Кая чиләк?
Су да эчерим әле».

Чишмә суы белән сыйлый
Машинасын Хәйләпүш.
Бик шәп китсен, илләр гизсен,
Дан казансын Хәйләпүш!

Утырды, рульгә тотынды,
Авызлары колакта:
— Әти-әни, сау булыгыз,
Киттем ерак-еракка! —

Кул селки... Артка караса,
Бер адым да китмәгән.





Башын кашый: — Ахры моңа
Бераз хәйлә җитмәгән.

Әһе! Белдем нишләргә! —
ди,—
Сүтеп карыйк без моны,
Төрле-төрле әмәл белән
Корып карыйк без моны.—

Көпчәкләрен бер аска,
Бер өскә куеп карый,
Алдан-арттан этеп карый,
Рулен дә борып карый.

Бер чиртеп карый моторга,
Бер аңа өреп карый,
Аһ-ваһ килеп машинасын
Күтәреп йөреп карый.

Хәйләли торгач шулай,
Тиргә батты Хәйләпүш.
Тирен сөртеп, тастымалын
Читкә атты Хәйләпүш.


Сигнал бирми машина,
Гүләп китми машина.
Утыру кая!
Хәйләпүшнең
Кайгы төште башына.

Их, Хәйләпүш олы юлдан
Җилдереп узса икән!
Аюларның, куяннарның
Күзләре кызса икән!

Йокысы качты, аштан калды,
Авыру алды егеткәй,







Әмма үзенең хыялына
Тугры калды егеткәй.

— Әһә! — диде Хәйләпүш,
Киеп алды кәләпүш.—
Бөтен хикмәт кәләпүштә! —
Дип шатланды Хәйләпүш.

Машина ясау хәйләсе
Тик кешегә хасмыни?!
Кәләпүш кисә, Хәйләпүш
Машина кормасмыни?!

Җиң сызганып, күкрәк киереп
Янә эшкә кереште.
Дер селкетә машинасын:
— Хәйләлим,— ди,— бу эшне!

Алгы күчәрен күтәреп
Каенга сөяп карый.
— Төлкеләргә сары төс,— дип,
Сарыга буяп карый...

Ә шулай да сигнал бирми,
Йөреп китми машина.
Ни кыланса да Хәйләпүш,
Пошмый-нитми машина.

Тигездән этте — бармады,
Биек тауга ашмады,
Түбән таба таштан ташка
Мәтәлчекли башлады.

Әле ярый Хәйләпүшкәй
Читкә ыргып котылды!

Бар хәйләдән ике йөктәй
Утын чыкты — шул булды...

Кәләпүшне — файдасызны
Атты-бәрде Хәйләпүш:
— Агач башындагы кошка
Оя булсын кәләпүш! —

Каш җимереп, ирен тешләп
Карап тора бу егет.
Үзе эчтән бик дөрес бер
Хәйлә кора бу егет:
— Анакаем Кызыл Койрык
Киңәш бирәлмәс миңа,
Атакаем Майлы Мыек
Ярдәм итәлмәс миңа...

Чишмә башы каенлыкта
Яңа мәктәп бар икән.
Шәп инженер булыйм дисәң,
Шунда гына бар икән.

Куяннар, аю, керпеләр
Укырга җыела ди.
Дуртле-бишлеләр хөрмәттә,
Икеле — тыела ди...

Укы да яз, сызымнар сыз,
Һөнәрләр, фәннәр өйрән!
Һәр эшне эшләп була ди
Белем һәм хезмәт белән.

Җәй генә үтсен әле,
Көз генә җитсен әле,
Хәйләпүшкәй тау буеннан
Мәктәпкә китсен әле!..

Бик күп төрле машинаның
Серен чишәр Хәйләпүш.
Илләр гизәр, сулар кичәр,
Күккә менәр Хәйләпүш!



# ТАҢ СУКМАГЫ ҺӘМ ЯЛКАУ МАЛАЙ ХАМАДАН

Минем энем Рамазан
Тәмам чыкты чамадан.
Тактым аңа кушамат —
Хамаданмы, Хамадан!

«Вәгъдә — кармак салырга
Таңнан торып барырга!»
Шулай диеп сөйләштек тә
Тыныч йокы теләштек.

Менә иртән таң атты,
Мине әтәч уятты.
— Йә, Хамадан, тор инде,
Булгач, егет бул инде! —

Мымм-мымм, диеп мөгрәнде дә
Баштан болай бөркәнде.
Тора алмый Хамадан,
Йоклап китте яңадан.

Бер әйтүдән тормагач,
Сүзенә хуҗа булмагач,
Аннан юлдаш чыгармы да
Юлы аның уңармы!..

Алдым җимем, кармагым,
Ялгыз гына атладым.

Юлга чыктым — ниләр күрдем?
Их, дөнья матур икән!
Туган җирләр гүзәллеген
Таңнан торып күр икән.

Кояш чыга нур чәчеп,
Кошлар сайрый гөрләшеп.

Алтынланып офыкта
Яна җиңел болытлар.

Тау буйлары — карама,
Алсу томан тарала.

Таң һавасы чишмәдәй саф,
Аккошлар коенган күк,
Үләннәргә чыклар түгел,
Йолдызлар коелган күк.

Тракторлар басуда,
Эшләп йөри барсы да.

Сыерлар чыга көтүгә.
Сөт ташучы машина
Каз-үрдәккә гудок бирә,
Җәйләүгә дип ашыга.

Еракларга юл тотып
Очып бара самолет.

Су өсләре, яр буйлары
Карап кына торырлык,
Күктә — тургай, талда — кәк-
күк, —
Тыңлап кына торырлык!..

Минем килеп җиткәнне
Суда чабак, корбаннар
Ярты таңнан уянып
Көтеп кенә торганнар.

Җилле-җилле балыклар
Берәм-берәм каптылар,



Зәңгәр чиләк эченә
Өелешеп яттылар.

Ике аякны ат итеп
Кайтып җиттем ялт итеп.

— Дәү әни, кыздыр балыкны,
Сыйлыйк әле халыкны!

Дәү әти килер табынга,
Сеңелем килер табынга,
Бик зур булып утырырмын
Үзем табын янында.

Әти-әни, абый-җиңги,
Җизни белән апалар,
Эштән кайткач, мактый-мактый
Авыз итеп карарлар...—

Мин кайтканчы Хамадан
Йоклап яткан яңадан.

Юрганыннан нык тарттым,
Икенчели уяттым.

Мин йөргән таң сукмагыннан
Ул ялкау бер йөрерме?
Мин күргән матур иртәне
Ул мескен бер күрерме?..

Тәмле балык исләренә
Торып килә Хамадан.
Күзе йомык, авызы ачык,
Битен-кулын юмаган,
Мин судан тоткан балыкны
Ул тотмакта ... табадан.



## КИТАП УКЫЙБЫЗ

Әни безгә китап алды,
Нинди китап дип сора!
Биттән биткә рәсемнәре
Ачылып кына тора.

Мин карыйм рәсемнәрен,
Апам укый сүзләрен,
Әни безгә карап тора,
Нурландырып күзләрен.

## БУЯУ КАЛӘМНӘРЕ

Кызыл каләм — бер бизәк,
Зәңгәр каләм — бер бизәк,
Кәгазь бите ак икән лә,
Аны бизәргә кирәк!

Зәңгәре чәчәк ясый,
Яшеле тирәк ясый,
Сарысы кояш төшерә,
Кызылы флаг ясый.

## ГАЛИЯНЕҢ КҮЛМӘГЕ

Аклы күлмәген
Безнең Галия
Бигрәк тә инде
Яратып кия.

Ничек яратып
Аны кимәсен?
Үзе таккан бит
Зәңгәр төймәсен!

## УЙНАК ТУП

Зәңгәр тубым сикерә:
— Туп, туп, туп!
Мин качамын, ә син мине
Тот, тот, тот.

Читкә очам — артымнан
Җит, җит, җит!
Мин дә уен яратам,— ди,—
Бик, бик, бик.

## ТӨКЛЕТУРА


Төклетура кара тунын
Эчен тышка киеп алган,
Билдә — алтын пута, иңгә
Сары ефәк шарф салган.

Авыр гына, ялкау гына
Кыймыл-кыймыл кыймылдый
ул,

Сары чәчәк тәлинкәсе
Баллы икән, баллы, ди ул.

Чәчәкләр күп. Кояш. Җылы.
Ә шулай да Төклетура
Тунын салмый. Кыш чыгарга
Йонлач тун бик кирәк була.





## СЫЕРЧЫКЛАР

Җырчы кошлар
Сыерчыклар
Очып килгән ерактан,
ерактан.
Безгә килгән,
Безгә кунган,
Оябызны яраткан,
яраткан.

Таңнан торып,
Нурга чумып
Кагына-кагына җырлыйлар,
җырлыйлар.
Бар илләрдән,
Бар җирләрдән
Ямьле сезнең җир, диләр,
җир диләр.

## КЫР КАЗЛАРЫ

Кыр казлары,
кыйгак-кыйгак!
Кыр казлары,
кыйгак-кыйгак!

Күкләрдә очасыз,
очасыз,
Күлләргә төшәсез,
төшәсез.

Безнең якта
тугансыз ла,
Зуп-зур кошлар
булгансыз ла,
Очасыз кайларга,
кайларга,
Кышларсыз кайларда,
кайларда?
Кар-бураннар узгач,
узгач,
Яз чәчәкләр сузгач,
сузгач,
Кайтыгыз, казларым,
казларым,
Кайтыгыз, казларым,
казларым!

## КОЯШ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР

Кояш ятып йоклагач,
Күзен ача йолдызлар.
Кояш тора башлагач,
Күзен йома йолдызлар.

Кояш яктырткан чакта
Йоклап ала йолдызлар.
Кояш йоклаган чакта
Карап тора йолдызлар.

Карап тора йолдызлар,
Жырлап тора йолдызлар:
— Кояш нинди дәү,— диләр,—
Әлли-бәлли, бәү,— диләр.

## ГАРИФ БАБАЙ

Бар иде безнең авылда
Гариф атлы бер бабай.
«Аксакал» дип йөртсәләр дә,
Карт түгел иде алай.

Өйдән өйгә йөри-йөри
Мичләр чыгара иде.
Тузганнарын сүтеп ташлап,
Яңадан сала иде.

Кирпечләрен тезеп кенә
Ясый төтен юлларын...
— Бабай, мичең ай-һай матур,
Алтын икән кулларың! —

Бабай әйтә: — Мондый мичкә
Берни түгел салкын кыш.
Яңа мичкә — коры утын,
Хуҗаларга — мул тормыш! —

...Гариф бабай вафат инде,
Ахры күпне кичергән.
Улы укып эшкә керде
Туры домна миченә...

Бар иде безнең авылда
Гариф атлы бер бабай.
«Аксакал» дип йөртсәләр дә,
Карт түгел иде алай.
Бар иде...
Юк, ул үлмәгән,
Әйтик әле шунысын:
Һәрбер өйдә калдырган ул
Йөрәгенең җылысын!





## ТЕЛЕВИЗОР КАРЫЙБЫЗ

Кәрим белән Кәримә,
Сәлим белән Сәлимә —
Ике малай, ике кыз
Телевизор карыйбыз.

Утырабыз шым гына,
Шым гына, тып-тын гына.

Киносы да киносы —
Октябрь революциясе!

Менә Ленин торып басты:
— Сугышып алыйк,— ди,—
властьны! —

Ул декретлар әзерли,
Чын бәхет декретлары.
Үзен дошманнар әзәрли,
Юк итмәкчеләр аны...

Аврорадан залп бирәсе,
Зимнийны аласы бар,
Советлар власте ясап
Яңа юл ярасы бар.

Мең төрле борчу бер җанга —
Хәлиткеч көрәшләр алда!

Көн-төн ялсыз, таң атканда
Ильич түшәк салмакчы,
Баш астына китап тезеп,
Черем итеп алмакчы.
Без аңлыйбыз, без зирәк:
Батырга да ял кирәк.

Ильич йокыга талды,
Бүлмә дә тынып калды.

Ялгыш кына төчкереп
Куйды шунда Кәримә.
— Төчкерме тор, уятасың! —
Диде аңа Сәлимә.

Революция җиңгәнче,
Ильич сәхнәгә менгәнче
Карадык без шым гына,
Шым гына, тып-тын гына,
Соңыннан без дә шаулаштык:
— Ур-ра! — диеп кул чаптык.

## ЭЧТӘЛЕК


**Әкиятләр**

Остакул Гаффар һәм кырык юлбасар турында табышмаклы әкият 4

Төлке улы Хәйләпүш 12

**Шигырьләр**

Таң сукмагы һәм ялкау малай Хамадан 18

Китап укыйбыз 20

Буяу каләмнәре 20

Галиянең көлмәге 20

Уйнак туп 20

Төклетура 20

Сыерчыклар 21

Кыр казлары 21

Кояш һәм йолдызлар 22

Гариф бабай 22

Телевизор карыйбыз 24